КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 9 август г.Казань № 642

Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Кararга теркәлгән Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 30 гыйнвар, 48 нче карары белән расланды

Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба - Фонд) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар (алга таба - бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана торган финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтү дәүләт гарантияләре программасы белән билгеләнә торган юнәлешләр буенча мәҗбүри медицина иминияте системасы аша медицина оешмаларын гамәлгә ашыруга Фонд бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан нигездә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга бирелә.

Әлеге Тәртипнең гамәли көче Татарстан Республикасы бюджетыннан Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый:

Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү;

Медицина ярдәме (ашыгыч махсуслаштырылган медицина ярдәме) күрсәтү максатларында авиация хезмәтләрен сатып алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү;

Татарстан Республикасы медицина оешмаларының ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник онкология диспансеры» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең һәм «Түбән Кама үзәк район күппрофильле хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең паллиатив медицина ярдәме бүлекләре күчмә бригадаларының машина йөртүчеләренә эшчәнлекләренең үзенчәлеге өчен өстәмә акчалата түләүләр;

Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм медицина оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы айлык акчалата түләүләр;

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак протезлары буенча хезмәтләр күрсәтү.

3. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша тотыла.

4. Бюджетара трансферт акчасы Фонд тарафыннан Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган шәхси счет аша тотыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Министрлыкка җиткерә.

6. Министрлык Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәре җиткерелгән көннән алып биш эш көне эчендә Министрлык һәм Фонд арасында төзелә торган бюджетара трансфертлар бирү турында килешү (алга таба - Килешү) нигезендә Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар бирә.

7. Фонд:

медицина оешмалары белән төзелгән шартнамәләр нигезендә медицина оешмаларына әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын күчерә;

квартал саен, хисап аеннан соң килүче айның 20 числосыннан да соңга калмыйча, Килешүдә билгеләнгән форма буенча бюджетара трансфертларны тоту турында Министрлыкка хисап тапшыра.

8. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата Фонд тарафыннан файдаланылмаган бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемενә кире кайтарылырга тиеш.

Бу Тәртип нигезендә алынган акчаның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәнә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карарны, күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән алып 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык кабул итә.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карар нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән, күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган Фонд бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен бирелгән Фонд бюджеты керемнәнә кире кайтарылырга мөмкин.

9. Министрлык һәм Фонд Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын бирелгән медицина оешмалары тарафыннан түбәндәге очракларда өлешчә яисә тулысынча кире кайтаруны тәэмин итәләр:

әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда (кимегәндә);

медицина оешмалары тарафыннан акча максатчан файдаланылмаганда.

10. Бу Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән очракларда медицина оешмаларына бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы Фондның тиешле таләбен алган көннән алып 15 көн эчендә Фонд бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмалары тарафыннан акчаны кире кайтару срогы бозылганда Фонд бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән 30 көн эчендә акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

11. Фонд әлеге Тәртипнең 9 пунктында каралган нигезләр буенча медицина оешмаларыннан кергән акчаларны Фонд счетына күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы Федераль казначылык идарәсендә ачылган көннән алып өч көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кайтара.

12. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык һәм Фонд тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.